# КАРАР
# Татарстан Республикасы Азнакай район Советы

Азнакай шәһәре №336-45 «12» март 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 30 мартындагы 177-27 нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлекләрендә шәһәр төзелеше проектлаштыру нормативларын раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлекләрендә шәһәр төзелеше проектлаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү хакында (13.12.2018 №222-32, 23.05.2019 №266-36, 20.08.2019 №284-38, 22.10.2019 №291-39, 12.12.2019 №304-41карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексын үтәү йөзеннән, 2012 елның 10 июлендәге 117-ФЗ номерлы «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында Техник регламент» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә

**Азнакай район Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 30 мартындагы 177-27 нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлекләрендә шәһәр төзелеше проектлаштыру нормативларын раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлекләрендә шәһәр төзелеше проектлаштыру нормативларына (13.12.2018 №222-32, 23.05.2019 №266-36, 20.08.2019 №284-38, 22.10.2019 №291-39, 12.12.2019 №304-41карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.2 бүлектә 5.2.93 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Автомобильләргә хезмәт күрсәтү объектларыннан күрше объектларга кадәр ераклыкны Шәһәр төзелешенең СП 42.13330.2016, СНиП 2.07.01.-89 таләпләренә туры китереп кабул итәргә кирәк. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документларының СанПиН

2.2.1/2.1.1.1200-03 исәпкә алып башкарылырга тиеш.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай район Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин